Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы
Исләй авыл җирлеге Советы

КАРАР

25 март 2024 ел №41/1

«Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы " Исләй авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге милкендәге муниципаль милекне хосусыйлаштыру тәртибен раслау турында " 2019 елның 24 сентябрендәге 66/1 номерлы Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Исләй авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

"Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 24.07.2023 ел, 370-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Советның 24.09.2019 ел, 66/1 номерлы карарына Чистай шәһәр прокуратурасының 16.02.2024 ел, 02-08-02-2024 номерлы протестын карап чыгып, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Исләй авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Исләй авыл җирлеге Советының "Муниципаль милекне хосусыйлаштыру тәртибен раслау турында" 2019 елның 24 сентябрендәге 66/1 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының " Исләй авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге милкендә булган муниципаль милекне хосусыйлаштыру тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1.1.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1.9. Әгәр әлеге Федераль закон белән башкасы билгеләнмәгән булса, кече һәм урта эшкуарлык субъектларының арендага алынган муниципаль күчемсез милекне хосусыйлаштыруда катнашу үзенчәлекләре федераль закон белән билгеләнә.";

1.2. 7.4 пункт түбәндәге эчтәлектәге 16 һәм 17 пунктчалар белән тулыландырылырга:

"16) мондый милекне җәмәгать сервиты һәм (яки) әлеге Федераль закон һәм (яки) башка федераль законнарда каралган чикләүләр белән йөкләүне билгеләү турында мәгълүмат;

17) конкурс шартлары, формалары һәм аларны үтәү вакыты.";

1.3. 13.2 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"әлеге Федераль закон нигезендә мондый килешүне яклар үтәү өчен мәҗбүри булган башка шартлар, шулай ук мондый килешү яклары тарафыннан үзара килешү буенча билгеләнгән башка шартлар".

2. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә игълан итәргә һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга www.chistopol.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Ислэй авыл җирлеге Советының законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Ислэй авыл җирлеге
башлыгы Чернышев В.П.